# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Зур Нөркәй авыл җирлегенең Зур Нөркәй авылы торак пунктында
2025 елда үзара салым кертү турында

**2024 елның 22 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлегенең Зур Нөркәй авылында гражданнар җыены

## КАРАР БИРДЕ:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге Зур Нөркәй авыл җирлеге территориясендә 1 төркем инвалидлар, көндезге уку йортлары студентлар, дүрт һәм аннан да күбрәк бала белән күп балалы гаиләләр, хөкем ителгәннәр, Украина территориясендә махсус хәрби операция катнашучылар һәм гаилә әгъзаларыннан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1. Махсуслаштырылган техниканы карап тоту «Беларус-82.1» тракторы (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү);
2. Зур Нөркәй авылында урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (урам яктырту утларын сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырту челтәрләрен карап тоту һәм аларга техник хезмәт күрсәтү);
3. Зур Нөркәй авылында җәйге вакытта территорияне чабу (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү) ;
4. Зур Нөркәй авылында зират территориясен койма белән әйләндереп алу (төзелеш материаллары сатып алу, зират территориясен койма белән әйләндереп алу (килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
5. Зур Нөркәй авылының зиратларында агач кисү;
6. Зур Нөркәй авылы территориясендә көнкүреш калдыклары һәм чүп-чарны вакытлыча туплау урыннарын җыештыру (хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);
7. Зур Нөркәй торак пунктында янгын гидрантлар сатып алу һәм урнаштыру;
8. Зур Нөркәй авылында урамындагы авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш салу белән чокырларны ремонтлау, таш ташу).

2. Әлеге карарны Зур Нөркәй авыл жирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматнын рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Башкарма комитет җитәкчесе вазифаларын башкаручы
Зур Нөркәй авыл җирлеге
Сарман муниципаль районы
Татарстан Республикасы ______________ А.Н.Сабитов